
# БЕР НУР БУЛСЫН КҮҢЕЛ ЙОЛДЫЗЛАРЫМ



***Хәмит Латыйпов*** Илеш районының Бүләр авылында туган. Һөнәре буенча... Була бит шундый шәхесләр, нәрсәгә генә тотынса да көлдереп куя. Һәм аларның төп һөнәре нәрсә икәнен дә ачык кына әйтә алмыйсың. Эх, куллары алтын шул аның, дип сокланырга гына кала.

Хәмит тә менә шундыйлардан. Керамикага тотынсынмы, кисю (резьба) сәнгатенәме, графикагамы — һәр эше җанга ятышлы булыр. Ул озак еллар буе Туймазы фарфор заводында да эшләгән. Завод чыгарган савыт-сабалардан матур-матур бизәкле рәсемнәрне күргәнегез бардыр инде. Әйтик менә «Сердәшләр», «Урал батыр», «Җыр», «Айсылу» кебекләрен. Болар бар да Хәмит Латыйповның иҗат җимешләре булыр. Хәтта шундый кечкенә рәсемнәрдә дә ягымлы бер хис чагылып кала.

Болары чәчәкләре генә әле. Ә инде картиналарына килсәк... Аның һәрбер эше мәгънәви тегәллеге, тирән фикерләрне дә, катлаулы күренешләрне дә гади, аңлаешлы итеп бирә белүе белән аерылып тора. Монда бер генә артык нокта дә тапмассың, барсы да үз урынында, барсы да табигый. Хәмитнең иҗатын нинди мәктәпкә, нинди агымга бүлгәләү мөмкин түгел. Аны бернинди калыпка да салып, сыйдырып булмый. Чын талант шулай булырга тиештер дә.

Әлбәттә, картиналарын чит илләрдә дә, Русиядә дә, Татарстанда да, Башкортстанда да яраталар, сатып алалар.

Тагы шунсын да әйтергә кирәк, Хәмит ифрат күп эшли. Узган кышны гына йөз иллеләп хезмәт тәмамлаган. Әле шуларның утыз өчен Уфага алып килгән. 1 сентябрьдә Башкортстан Рәссамнар берлегенең кече залында шәхси күргәзмәсе ачылды. Моны ул Бөтендөнья татарларының II Конгрессына багышлаган. Күргәзмәдә халкыбыз язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге хакында фәлсәфи уйларга этәреп, күңелдә берчә сагаю, берчә якты өметләр уятырдай әсәрләре тупланган. Ул ике атна буе дәвам итә. Мөмкинлеге була торып та, Хәмит Латыйповның картиналарын барып карый алмаган кеше, әлбәттә, күп нәрсә югалтачак.

Моннан тыш, Хәмит шигырьләр дә яза. Шигырьләре йөзгә кызыллык китерерлек түгел. Аларны укыганда гасырлар мәгърурлыгын, вакыт агышын, галәмнәр моңын тоясың. Хәтта кайберләре без өйрәнгән шигърият кануннарына ярашып бетмәсә дә, кул тидерәсе килми, аларны шагыйрьнең күңел халәте буларак кабул итәсең.

Кадерле укучыларыбыз, сезгә Хәмит Латыйповның шигырьләрен тәкъдим итәбез. Ә картиналарын үзегез күргәзмәгә барып карагыз.

## Борчылу

Гомер ишекләрен, вакыт кага-кага
Язмыш тагын тормыш арбаларын тарта,
Күпме генә тырышсам да уйламаска
Кайгыларым, борчуларым һаман арта.
Киләчәккә карап, салып хыялларны
Истәлекләр үткәннәргә кайта.
Үткән саен сикәлтәле гомер юлын
Борчылудан өметсезлек арта.
Томаннарга төренгән язмыш
Көзге кебек уч төбендә ята.
Төшенәсең үткән саен гомер юлын
Үткәннәрем булган икән хата.

## Сынау

Күпме генә типкәләде, суккалады
Кирәксезгә бу язмышлар мине.
Һаман өстерәлә тормыш сукмагында
Үҗәтләнеп гарип сукбай шикелле.
Баштан күпме авырлыклар узган,
Күрми микән әллә тәкъдир күзе.
Кичәргә дип тормыш сынауларын
Язган микән әллә, Ходай үзе.

## Хыял



Кош канаты, хыялларым сахраларда
Җилгә әйләнеп бәрелә ул кыяларга.
Томырылып атыла да упкыннарга,
Күккә менеп урала ул йолдызларга.
Далалар тар, урын җитми хыялларга,
Галәмнәргә ак юлларын сузалар да
Тагын оча бирешмичә давылларга,
Адаштырып караңгыны бураннарда.

## Сиңа

Кимчелекләрем дә күптер инде
Хәтта күбрәктер башкадан.
Хәтеремдә әле әйткән
«Гомеремдә сине ташламам!»
Язмыш юлы инде икебезне
Ике якка илтеп ташлаган.
Язмышларга тик үпкәләп



Бәхетләрең булгач башкадан.
Гомерләр дә инде үтеп бара,
Чәчләрем дә агара башлаган.
Рәшәләрдән аваз килә һаман:
Гомерем буе сине ташламам,
ташламам,
ташламам...

## Балачакка кайту

Бер утрау кебек үткәннәрдән
Ераклаша бара балачак.
Киндер ыштан кигән кара малай
Яшь тай булып яшел болыннарда
Бала чагым озатып барачак.
Еракларда зәңгәр болытларга
Кайтсын-кайтсын, диеп елаган
Хыял булып йолдызлардан таңда
Киләчәккә юллар салачак.
Ятимлекләр җанны өзсәләр дә
Күңел йолдызларым бер нур булып
Өметләргә ышаныч салачак.
Язмышларда адашкан кош булып
Ак хыяллар, ак җилләргә тотынып
Балачакка кайтып барачак.

